| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР<br>СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 10.03.2025 | № 90 |

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Менделеевск шәһәре территориясендә
төзекләндерү өлкәсендә муниципаль
контроль турында нигезләмәгә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында һәм Менделеевск районы прокурорының килгән протестлары нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәр Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2022 елның 3 октябрендәге 43 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5.6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә « " 5.6.4. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 5 өлешендә каралган очраклар керми».

1.2. 5.7.10 тунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "5.7.10. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 71нче өлешенә әверелергә тиешле очраклар керми».

1.3. 5.9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә « " 5.9.5. Урынга барып тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча, контроль төре турында Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.

1.4. Түбәндәге эчтәлекле 5.9.7 пункты белән тулыландырырга. "5.9.7. Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә күрсәтмә бирү турында Карар кабул ителергә мөмкин, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты

законында күрсәтелгән очракта».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм экология мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Шәһәр Советы рәисе Р.И. Беляев